Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре

“Алсу” балалар бакчасы мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем учреждениясе

# “Каз өмәсе”

(6-7 яшьлек балалар өчен әдәби-музыкаль кичә)

Тәрбияче: Асылмарданова Ф.Ф.

30 октябрь 2014ел.

# «Каз өмәсе»

**6-7 яшьлек балалар өчен әдәби-музыкаль кичә**

**Максат:** Бәйрәм көннәре турында күзаллауларын формалаштыру. Балаларны милли бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү. Халык бәйрәмнәренә, гореф-гадәт һәм йолаларына ихтирам тәрбияләү. Бәйрәм тантаналарына уңай мөнәсәбәт булдыру.

**Җиһазлау:** Милли киемнәр, “казлар”, канатлар, чиләкләр.

Алдан эшләнгән эшләр:

1 Бәйрәмнәр турында әңгәмә үткәрү

2. Җырлар, шигырьләр, бию, уеннар өйрәтү

3. Залның бизәлешен уйлап табу.

4. “Каз түшкәләре” тегү.

**А.б.** Хәерле көн, кадерле кунаклар.Бүген без татар халкының традицион бәйрәме-каз өмәсенә җыелдык. Каз өмәсе ул татар халкының иң көтеп ала торган күркәм йолаларның берсе.Ба-лалар, ягез әле, уйлагыз, безнең халык казны нинди максаттан чыгып асраган?

**1б.**Каз мамыгыннан мендәрләр, түшәкләр, ястыклар ясаганнар.

**А.б.** Дөрес, тагын.

**2б.**Каз итеннән аш-су, күп төрле каз ашлары да әзерләгәннәр.

**3б.**Каз маен дәва өчен кулланганнар.Кышкы суыкларда бит, колак очлары өшесә, каз мае сөрткәннәр.

**А.б.** Ә менә пар каз туйның хөрмәтле күчтәнәче булган. Хәзер дә шулай дәвам итә.

**Бабай**: Әбисе, кара әле, бүген Сәмигуллаларда каз өмәсе икән бит. Әллә, мин әйтәм, без дә казларны йолкып алыйкмы, дим. Казларыбыз бик таза, матур булып үстеләр. Аллага шөкер.

**Әби**: И бабасы, мин сиңа әйтергә оныткanмын гына, картлык- яшьлек түгел шул. Кичә мин кызларны каз өмәсенә чакырып кайттым.

(ишек шакыйлар)

Әллә, кызларыбыз килеп тә җиттеләр инде.

**Кызлар:**Исәнмесез әби, бабай. Менә, без каз өмәсенә килдек.

**Әби**: бабай кая син, чык кызлар килептә җиттеләр.

**Бабай**: Чыгам, карчык, изге сәгатьтә балалар.

**Әби**: Әйдәгез, балакайларым, бауларны алыгыз.

**(кызлар бабай артыннан чыгып китәләр, маг-да каз тавышы ишетелә, кызлар каз тотып** керәләр**.**

**М.Камилә**: Көзләр җиткәч җырлый-җырлый,

Казлар йолкый кыз бала.

Авылларда хәзер каз өмәсе,

Өмә җыры һәрбер ызбада.

**Х.Әдилә:** Кыйгак-кыйгак дип кычкыра,

Әллә киек казлармы?

Җырлап-биеп каршы алыйк

Быел килгән көзләрне.

**З.Лиана:** Көз көннәре бигрәк ямьле,

Өмәгә килгән кызлар.

Матур булсын каз өмәсе,

Әйдәгез,җырлыйк, кызлар!

**Җыр:**Дүдәк- дүдәк.

**Бала:** И,кызлар, миңа бигрәк зур, симез каз эләкте.

**Бала:** Әйе, быел бигрәк уңды шул казлар.

**Бала:**Аллага шөкер, казлар бик симез булды.

**А.б.** Йонын йолкып бетергәч, каз каурыйларын елга буена, тыкрыкка, сукмакларга чәчәләр. Бу- киләсе елда каз күп үссен, йортка тезелеп кайтып керсен дигән теләк белән эшләнә.

**М.Камилә** (каурый чәчә)

Алдан барсын әнкәсе, арттан барсын әткәсе.

Пипелдәшеп йөгереп барсын 25 бәбкәсе.

**Әби:** Ай,булдырдыгыз кызлар.Бигрәк чиста йолкыдыгыз. Әйдәгез, казларны юып та кайтыгыз инде.

*(*кызлар *казларны көянтәгә элеп китәләр. Малайлар да иярә)*

**ҖЫР:"К**ыз балалар  каз юалар"(малайлар җырлый.)

(*КЫЗЛАР  КАЙТАЛАР, КАЗЛАРНЫ ӘБИГӘ  БИРӘЛӘР)*

**Эльдар:** Кызлар, кич белән  бәлеш  ашарга килсәк кертәсезме?

**З.Лиана:** Күчтәнәчегез булса кертербез.

**Рифат:** Анысыннан гына тормабыз. ( ишек шакыйлар)  Ник кертмиләр инде,ишек тә ача белмиләр. Торабыз өшеп катып, китәрбез әле кайтып.

**С.Лиана:** Ашыкмагыз әле, исәнләшегез баштан.

**М-й:** Әссәламәгаләйкем.

**Кыз-р:**   Вәгаләйкем-әссәлам.

**Кыз:** Егет, сиңа ни кирәк?

**М-й:** Каз, мамык, ястык кирәк.

**Кыз:**Казларыбыз мамыксыз,

Кызлар йоклый ястыксыз

Шуны да син белмәгәч,

Йөрмә монда вакытсыз.

**Кыз:** Егет, сиңа ни кирәк?

**М-й:** Безгә  матур кыз кирәк.

**Кыз:**Ул кызыбыз бик елак.

**М-й:**Конфет, прәннек бирербез.

**Кыз:** конфет, прәннек кирәкми.

**М-й:** кирәкмәсә эләкми.

**Әби:** Аптыратмагыз инде егетләрне, кертегез.

(малайлар керә, кызлар каршына утыра) Балакайлар, матур гына утырыгыз, мин күршеләргә керәм.

**Кара- каршы басып** җырлыйлар**"Челтәр элдем читәнгә"**

**Х.Әдилә**: Әйдә, дустым, алып барам

Алма коелган җиргә.

Бер җырламый булмас инде

Дуслар җыелган җирдә.

**Рифат**: Җырла-җырла дип әйтәсез,

Җырчы егет мин түгел.

Кычкырып җырлап җибәрсәм,

Артисттан да ким түгел.

**Җырлый**: Сары каеш дилбегәләр

Безнең атларда гына

Иртән торсам ике күзем

Сезнең якларда гына.

Безнең авыл зур авыл, зур авыл матур авыл,

Безнең авыл егетләре менә шундый була ул.

**Эльдар**: Кызлар, егетләр, әйдәгез"**Чума үрдәк, чума каз"** уенын уйнап алабыз.

**М.Камилә**: Безгә килгән егетләр

Нигә килгәннәр икән.

Егетләрне биетик,

Ничек биерләр икән!

**(малайлар ялгыз бииләр)**

**С.**Лиана: Сандугачның балалары

Талга кунганнар икән.

Егетләребез бигрәк уңган,

Бигрәк булганнар икән.

Кызлар, егетләрдән калышмыйк. Әйдәгез бездә биеп күрсәтик.

**З.Лиана**: Каз канатын йомшак диләр,

Ә без шуны белмибез.

Казлар симез булсын өчен,

“Каз канатын” биибез.

**Бию:”Каз канаты”.**

**Илмир:** Әйдәгез, йөзек салыш уйныйбыз. “Йөзек салыш” уены.

**Самат:** Эх, күңелле өмәсе,

Шунда кызлар җыела.

Шунда уйнау, шунда көлү,

Шунда дуслар табыла.

**Җыр:**”Каз өмәсе”.(җыр бетүгә әби керә. Бигрәк матур җырладыгыз , биедегез, уйнадыгыз )

**Әби:** Менә, мин сезгә бик тәмле итеп бәлеш пешердем. Тәмләп чәй эчәрсез.

**А.Б.** Каз канатлары сибәбез,

Сез барасы юлларга

Каз өмәсе бәйрәмнәрен

Бергә үткәрергә язсын

Киләсе елларга да.

Кадерле балалар, эти- әниләр, бүгенге “каз өмәсен дә”, без сезгә татар халык җырларын, биюләрен, уеннарын уйнадык.

Мин сезгә исәнлек-саулык, тынычлык, бәхет, иминлек телим.